**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге составына керүче Яңа Кужак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

29 октябрь 2020 ел № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә - артезиан скважинасы һәм сууткәргечнең запас өлешләрен алу һәм урнаштыру, Яңа Кужак авылында юлларны төзекләндерүгә юнәлдерергә Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2020 елның 29 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучы 33 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 28 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 28 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге составына керүче Яңа Кужак авылында халык җыенын узган дип , халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Кужак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә - артезиан скважинасы һәм сууткәргечнең запас өлешләрен алу һәм урнаштыру, Яңа Кужак авылында юлларны төзекләндерүгә юнәлдерергә Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Кужак авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________________Д.Д. Абдрахманова

Яңа Чәчкап авыл җирлеге
башлыгы __________________Д.Д. Абдрахманова